РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

Глава
Алькеевского сельского
поселения
Азнакаевского муниципального
района

Пер.Советский,44а,
с.Алькеево, Азнакаевский
муниципальный район 423309
тел. ( 885592) 37-4-23

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

Азнакай муниципаль районы
Әлкәй авыл җирлеге
советы
БАШЛЫГЫ

Совет тыкрыгы, 44а
Әлкэй авылы, Азнакай муниципаль
районы 423309
Тел. (885592) 37-4-23


**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«02» ноябрь 2020 ел № 23

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл җирлегенең Кызыл Сукачы торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрү турында

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл җирлеге Уставы нигезендә, карар итәм:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл җирлеге Кызыл Сукачы торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2020 елның 14 ноябренә билгеләргә.

1.2. Билгеләргә:

-Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл җирлеген Кызыл Сукачы торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын үткәрүче - Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл җирлеге башкарма комитеты;

- халык җыенын үткәрү вакыты-2020 елның 14 ноябре, 10.00 сәгатьтән 11.00 сәгатькә кадәр;

- үткәрү урыны-Кызыл Сукачы авылы, Чапаев ур.,26 йорт (Галимов Илшат Таһировичның торак йорты)

1.3. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл җирлеге башкарма комитетына тәкъдим итәргә:

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл җирлеге Башкарма комитетында халык җыены карарына чыгарыла торган мәсьәлә буенча, 2020 елның 03 ноябреннән дә соңга калмыйча, гражданнарга материаллар белән танышу хокукын, түбәндәге адрес буенча тәэмин итәргә:

Әлкәй авылы, Совет тыкрыгы, 44а йорт, Кызыл Сукачы авылы, Чапаев ур., 26а йорт янындагы мәгълүмат стенды;

- сайлау хокукына ия булган, Кызыл Сукачы авыл халкы исемлеген төзергә;

- гражданнар җыенына мәгълүмати материаллар әзерләргә;

- Кызыл Сукачы торак пункты халкына массакүләм мәгълүмат чараларында һәм башка ысуллар белән гражданнар җыены турында хәбәр итәргә.

2. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез, 2021 елда 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм анда катнашучылар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, көндезге уку формасы

буенча белем алучы студентлардан тыш, Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл жирлеге Кызыл Сукачы авылы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны жирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга тоту белән ризамы:

- территорияләрне төзекләндерүне оештыру (Кызыл Сукачы авылында юлларны кардан чистарту).

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Әлеге карарны Әлкәй авылы, Совет тыкрыгы, 44а йорт адресы буенча урнашкан,

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл жирлеге башкарма комитетында һәм Кызыл Сукачы авылы, Чапаев урамы, 26а йорт адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендында Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru,

- Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы Азнакай муниципаль районының рәсми сайты «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru. урнаштырырга.

4. Әлеге карар ул халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

Башлык: С.З.Зиннурова